# Габдулла Тукай әсәрләренә дидактик уеннар

Габдулла Тукай татар халкының бөек шагыйре. Бөек шагыйрьнең әсәрләре күңелләрдә гаҗәеп шатлык, горурлык хисләре уята. Аның әсәрләрен олылар да, балалар да яратып укыйлар, тыңлыйлар. Сабыйлар күңеленә “Шүрәле”, “Су анасы” кебек әкиятләре белән кереп калган шагыйребез- балалар һәм аларны тәрбияләү мәсьәләләрен үз иҗатыннан, эшчәнлегеннән читтә калдырмый. “Мәктәптә милли әдәбият дәресләре” исемле уку китабында: “Балаларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен. Кечкенәдән үк гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре назик вәләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкадәс нәрсәләрне сөючән буладыр”,- ди Тукай. Яшь буынны тәрбияләүдәге зур ролен тирәнтен аңлаган шагыйрь балалар дөньясын чын сәнгать әсәрләре белән баета. Шагыйрьнең балалар дөньясын нечкәләп белүе, аларны якын итүе, кешелекле, эшчән, белемле, тәрбияле булып үсүләре өчен тирәнтен кайгыртуы, аның балалар өчен иҗат иткән әсәрләрендә чагыла. Габдулла Тукайның сабыйлар рухына ятышлы, теле ягыннан аңлаешлы әсәрләре балалар бакчаларында зур урын алып тора.  Балалар шагыйрьнең шигырьләрен ятлап, әкиятләрен тыңлап кына калмыйлар,бу әсәрләргә нигезләнеп төзелгән дидактик уеннар аша сүзлек байлыгын, сөйләм телләрен үстерәләр, өйрәнгәннәрне ныгыталар, аң- белемне, хезмәтне, туган җирне, туган телне яратырга өйрәнәләр.

# “Сүзләр төзе” уены.

**Максат:** Габдулла Тукай әсәрләрен, бишкә кадәр санау тәртибен, сүзләрнең дөрес әйтелешен, сүзләрне иҗекләргә бүлү күнекмәләрен, ө хәрефенең сүзләрдә язылу урынын ныгыту. Балаларда татар сүзләрен дөрес язу һәм уку теләге уяту. Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. Игътибарлылык, Тукай иҗаты аша туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Төлке, ут, күз, ат, йөзем рәсемнәре сурәтләнгән карточкалар, бу сүзләрне язу өчен әзерләнгән хәрефләр.

**Искәрмә:** Рәсемнәр сурәтләнгән һәр карточканың аскы уң почмагына саннар язылган: төлке-1, ут-2, күз-3, ат-4, йөзем-5.

**Уен барышы.**

1 ысул. Бала карточкада сурәтләнгән рәсемнәрне атый һәм шул сүзләрнең Габдулла Тукайның кайсы әсәрендә кулланылганын әйтә.

2 ысул. Рәсемле карточкаларның аскы уң почмагында язылган саннарга карап, тәртип буенча тезә һәм санап чыга.

3 ысул. Хәрефләр ярдәмендә рәсемгә туры килгән сүзне яза, ө хәрефенең сүзләрдә язылу урыны турында әйтә. Сүзләрне иҗекләргә бүлә.

4 ысул. Беренче баганада килеп чыккан яңа сүзне укый, иҗекләргә бүлә.



# “Без кайсы әкияттән?” уены.

**Максат:** Габдулла Тукай әсәрләренә нигезләнеп, авазларны  дөрес әйтү, сүзләрне берлек һәм күплек саннарда дөрес куллану күнекмәләрен ныгыту. Сүз байлыкларын, сөйләм телен, мөстәкыйль фикерләү, танып белү сәләтләрен үстерү. Игътибарлылык тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Габдулла Тукай әкиятләренең китап тышлыгына күчерелмәләр. Шүрәле, балта, бүрәнә, чөй, малай, эни, тарак, басма, тәрәзә, кәҗә, сарык, капчык, бүреләр, этләр, ут рәсемнәре сурәтләнгән  карточкалар.

**Уен барышы.**

1 ысул. Бала Г.Тукайның китап тышлыгы күчәрелмәләренә карап әкиятнең исемен әйтә.

2 ысул. Бала карточкаларда сурәтләнгән рәсемне атый, шушы сүзнең кайсы әкияттә кулланылганын билгели һәм китап тышлыгы янына куя, аларны берлек һәм күплек саннарда әйтә.

3 ысул. Әкият эчтәлеге буенча шушы сүзләрне кулланып җөмләләр төзи.




Габдулла
Тукай
Шүрәле


Габдулла Тукай
Кәҗә белән Сарык әкияте

# “Рәсем җыю” уены.

**Максат:** Г.Тукай әкиятләренә кызыксыну уяту. Сөйләм телләрен үстерү. Өлешләрдән бербөтен әйбер җыю күнекмәләрен ныгыту. Тырышлык, максатчанлык тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Бербөтен һәм диагональ яки вертикаль буенча берничә кисәккә киселгән Шүрәле, Су анасы, кәҗә белән сарык  рәсемнәре.

## Уен барышы.

Тәрбияче балаларны рәсемнәр белән таныштыра. Балалар рәсемнәрдә нәрсә сурәтләнгәнен әйтәләр. Аннан соң балалар өлеш буенча бербөтен рәсемне җыялар. Рәсемнәр буенча хикәя төзиләр. Уенны катландыру өчен, тәрбияче бербөтен рәсемне алып куя, ә балалар өлеш буенча рәсем җыялар.



# “Шакмаклар” уены.

**Максат:** Предметны, хәрәкәтне, билгене белдерүче сүзләрне, өлешләрдән бербөтен әйбер җыю күнекмәләрен ныгыту. Сүзлек байлыгын үстерү. Г.Тукай әсәрләренә кызыксыну уяту. Бер- береңә ярдәмчеллек, ихтирам, дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Шакмаклар, фишкалар, “Бала белән күбәләк”, “Кызыклы шәкерт”, “Сөткә төшкән тычкан”, “Шаян песи”, “Эш беткәч уйнарга ярый”, “Бишек җыры” шигырьләренә рәсемнәр.

**Уен барышы.**

Уенда берничә бала катнаша. Беренче бала үзенә охшаган рәсемне сайлап ала һәм рәсемдә Г.Тукайның кайсы әсәре сурәтләнгәнен әйтә, шакмаклар ярдәмендә бербөтен рәсемне җыя. Җыелган рәсем буенча калган балалар предметны, хәрәкәтне, билгене белдергән сүзләр әйтәләр(сүзләр кабатланырга тиеш түгел), ә рәсем җыйган бала дөрес җавап өчен фишкалар бирә һәм җиңүчене билгели. Калган рәсемнәрне җыю шул ук тәртиптә бара.



# “Яшел, ак, кызыл” уены.

**Максат:** Татарстан Республикасының Дәүләт флагында нинди төсләр булуын, аларның урнашу тәртибен һәм һәр тәснең нәрсә аңлатуын ныгыту. Сөйләм телләрен үстерү. Татарстан Республикасының Дәүләт флагына эстетик караш һәм хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Туры почмаклы яшел, ак, кызыл тасмалар.

**Искәрмә:** Ак тасма башкаларына караганда тарырак алына.

**Уен барышы.**

Һәр бала алдына кызыл, ак, яшел төстәге тасмалар куела. Тәрбияче уен барышында ел фасылларына багышланган табышмаклар әйтә:

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил- буран,-
Бу кайчак туган? (кыш)

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде;
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?-
Я, әйтеп кара. (яз)

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,-
Бу кайчак була? (җәй)

Балалар табышмакларның җавабын әйткәннән соң, тасмалар ярдәмендә ел фасылларының төсен билгелиләр һәм тиешле тәртиптә урнаштыралар.

Кыш- ак
Яз – яшел
Җәй- кызыл
Тәрбияче:

- Яшел белән ак тасманың урыннарын алыштырсак, нәрсә килеп чыга?
- Балалар: Татарстан Республикасының Дәүләт флагы.

Балалар төсләрнең нәрсә аңлатуын әйтәләр.
Яшел- тормыш, тере табигать төсе.
Ак- сафлык, чисталык, тынычлык, иминлек билгесе.
Кызыл- кояш, яшен һәм ут төсе.
Тәрбияче: Менә безнең Дәүләт флагыбызга нинди зур мәгънә сыйган.

